| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ СТЕПНОШЕНТАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ КЫР ШОНТАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** Кыр Шонталы авылы **КАРАР**

08.04.2022 № 26

«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Кыр Шонталысы авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү Тәртибен раслау турында» 2017 елның 25 сентябрендәге 48 номерлы Кыр Шонталысы авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указы нигезендә «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында һәм Алексеевск районы прокуратурасының 2022 елның 16 мартындагы 02-08-01 номерлы протестын карап,

Кыр Шонталысы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Кыр Шонталысы авыл җирлеге Советының 2017 елның 25 сентябрендәге 48 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Кыр Шонталысы авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү Тәртибен раслау турында» 3 пунктының «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең башка объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында

катнашу өлеше, пайлар), санлы финанс активлары, санлы валюта сатып алу буенча килешүләр (алыш-биреш суммасы) башкарылган акчалар, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хезмәткәрнең (эшченең) һәм аның хатынының (иренен) гомуми кеременнән артып китсә, соңгы өч елда алынган мәгълүматлар.".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Кыр Шонталысы**
**авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **Хамадеев Ф.Я.**